ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.03.2019 .Алексеевск ш.т.б. № 120

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, аларның җайлашуын һәм уңайлылыгын тәэмин итү максатларында инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда, инвалидларның торак урыннарындагы гомуми милекне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү турында» 2017 елның 13 февралендәге 52 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең"Инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, аларның җайлашуын һәм уңайлылыгын тәэмин итү максатларында инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда, инвалидларның торак урыннарындагы гомуми милекне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү турында" 2016 елның 9 июлендәге 649 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Дәүләт торак фонды, муниципаль торак фонды, шулай ук шәхси торак фонды составына керүче торак урыннарга карата инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, инвалидларның торак урыннарын җайлаштыру чараларын координацияләү буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органын билгеләү турында" 2016 елның 20 декабрендәге 958 нче карары нигезендәһәм закон таләпләренә туры китерү максатларында

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, аларның җайлашуын һәм уңайлылыгын тәэмин

итү максатларында инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда, инвалидларның торак урыннарындагы гомуми милекне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү турында» 2017 елның 13 февралендәге 52 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 нче кушымта Инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, аларның җайлашуын һәм уңайлылыгын тәэмин итү максатларында инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда, инвалидларның торак урыннарындагы гомуми милекне тикшерү буенча комиссия составын яңа редакциядә бәян итәргә (1 нче кушымта);

- 2 нче кушымтаның 3.16 пункты Алексеевск муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фонды, шулай ук шәхси торак фонды составына керүче инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми милекне тикшерү комиссиясе турында нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә«Чараларны чаралар планына кертү турында Карар кабул итү өчен бәяләмә, чыгарылган көннән соң 10 көн эчендә, муниципаль комиссия тарафыннан инвалидның тору урыны буенча муниципаль берәмлек башлыгына җибәрелә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары А. Н. Абакумовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
14.03.2019 № 120
карарына 1 номерлы кушымта

**Инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, аларның җайлашуын һәм уңайлылыгын тәэмин итү максатларында инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда, инвалидларның торак урыннарындагы гомуми милекне тикшерү буенча комиссия составы**

Кадыров Н.К. –Башкарма комитет җитәкчесе, комиссия рәисе

Абакумов А.Н. –Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, Рәис урынбасары

Семина Н.А. – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Алексеевск муниципаль районындагы халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәге директоры, комиссия секретаре (килешү буенча)

Комиссия әгъзалары:

Хамзина Е.А. – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Алексеевск районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча)

Свистунов И.К. – Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча)

Макарихина Е.С. – ветераннар иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча)

Седова Н.К. – инвалидлар иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча)

Кәлимуллин Т.Р. – Башкарма комитетның инфраструктура үсеш бүлеге башлыгы

_____________ – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча)

**Башкарма комитет эшләре**
**белән идарә итүче** **Г.А.Юсупова**